**Озынайтылган көн торкеме тәрбиячеләренең методик атналыгы**

Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләгәндә татар халкының әлектән килгән гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән кызыксынучы югары әхлаклы, һәряклап үсеш алган, иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

Бу максаттан чыгып түбәндәге бурычларны билгеләдек:

- тәрбия традицияләренә нигезләнеп халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү, алар белән кызыксынуларын үстереп баларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү.
- татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф-гадәтләре аша балаларның аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү.
- халкыбызның милли тадицияләрен саклау максатыннан ел фасыллары белән бәйләнешле йола-бәйрәмнәре белән балаларны таныштыру.

Соңгы елларда халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар арта башлады. Шул уңайдан күп кенә бәйрәмнәребез яңадан халык арасына кереп бара. Халкыбызның йола-бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен торгызу һәм яңарту безнең гимназиябездә дә актив алып барыла. Милли бәрәмнәр һәм гореф-гадәтләр, балаларыбызны халык культурасы белән таныштыруда, зур урын алып тора.

Менә шушы бурычларны хәм максатларны билгеләп озынайтылган көн тәрбиячеләре «Татар халкының милли йолалары» дип исемләнгән чаралар уздырдылар.

